| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА<br>И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ<br>ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

02.06.2022 № 180

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау хакында» 2021 елның 7 декабрендәге 450 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында бер төр нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 54 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмә раслау хакында» 2021 елның 7 декабрендәге 450 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6.6 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктатып тору турында министр карары,

әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш»;

6.7 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында министр карары, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш»;

6.8 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен яңартып җибәрү турында министр карары, әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Министрлык боерыгы белән расланырга тиеш».

Министр Ф.М. Хәнифов